ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
22.01.2025

**К А Р А Р**
№ 79

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппаратының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында» 2018 елның 12 февралендәге 371 номерлы карарына (21.05.2019 № 710, 10.02.2022 № 212 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 өлешнең 5.2 пунктында «электрон адрес» сүзләрен «, электрон почта адресы йә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланганда шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 5 өлешнең 5.3 пунктында «электрон адрес» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 5 өлешнең 5.6 пунктында (почта, электрон) сүзләрен «почта, электрон почта, йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 6 өлешнең 6.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 6.9.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«6.9.1 Миграция өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу ихтималы фактлары турындагы мәгълүматны үз эченә алган язма мөрәҗәгать теркәлгән көненнән алып биш көн эчендә федераль башкарма хакимият органының эчке эшләр өлкәсендәге территориаль органына, һәм Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органы җитәкчесенә), мөрәҗәгатьне җибәргән гражданга аның мөрәҗәгатен яңадан адреслау турында хәбәр итеп, әлеге Нигезләмәнең 5 пунктының 5.8, 5,9 пунктчаларында күрсәтелгән очраклардан тыш, җибәрелә.»

1.5 6 өлешнең 6.16 пунктында:

а) «Президент Аппараты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Аппараты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләренә алмаштырырга,

б) «район башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «аның адресына мөрәҗәгать кергән вазыйфаи зат яисә вазыйфаи зат вазыйфаларын вакытлыча башкаручы» сүзләренә алмаштырырга;

1.6. 6 өлешнең 6.21 пунктын «, электрон почта адресларына йә Бердәм порталдагы шәхси кабинетлар адресларына» сүзләре белән тулыландырырга;

1.7. 6 өлешнең 6.23 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты һәм РТ Министрлар Кабинеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Аппараты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләренә алмаштырырга;

1.8. 10 өлешне төшереп калдырырга;

1.9. 11 өлешнең 11.3 пунктын «электрон почта адреслары» сүзләреннән соң «йә 4 нче кушымта нигезендә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләре белән тулыландырырга;

1.10. 11 өлешнең 11.6 пунктында «(84365) 3-33-44» телефон номерын «8(84365) 2-30-67» номерына алмаштырырга

1.11. 12 өлешнең 12.4 пунктында «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен «Башлык» сүзләренә алмаштырырга;

1.12. 12 өлешнең 12.5 пунктында «Башкарма комитет җитәкчесе» сүзләрен «Башлык» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының « Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты Аппараты вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү тәртибен раслау турында 2018 елның 12 февралендәге номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 212 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин